**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 10 февралендәге 318 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 1 апрелендәге 916 номерлы «Казан шәһәре территориясендә реклама корылмаларын урнаштыру турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Казан шәһәрендә тышкы реклама өлкәсендә бердәм сәясәтне гамәлгә ашыру максатларында **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 1 апрелендәге 916 номерлы «Казан шәһәре территориясендә реклама корылмаларын урнаштыру турында»гы карарының (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 17 ноябрендәге 4009 номерлы, 2023 елның 20 апрелендәге 1143 номерлы, 2023 елның 17 июлендәге 1997 номерлы, 2023 елның 28 сентябрендәге 2864 номерлы, 2023 елның 10 ноябрендәге 3430 номерлы, 2024 елның 3 апрелендәге 1275 номерлы, 2024 елның 4 октябрендәге 4188 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 3 номерлы кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 121 биттә РП-21 номерлы ноктаны (урынны) төшереп калдырырга;

1.2. 166 биттә РП-248 номерлы ноктаны (урынны) төшереп калдырырга;

1.3. әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә 103 биткә КУ-15 ноктасын (урынын) өстәргә;

1.4. Казан шәһәре территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасына 10 номерлы кушымтада әлеге карарга 2 номерлы кушымта нигезендә таблицага 15 нче юл өстәргә;


1.5. Казан шәһәре территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасына 13 номерлы кушымтада 21, 247 нче юлларны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 10 февралендәге
318 номерлы карарына
1 номерлы кушымта




## ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР:

### I. Аерым торучы реклама корылмалары

- СС - суперсайт
- СБ - суперборд
- ББ - еврощит
- СР - ситиборд
- ПР - пилларс
- ПЛ - пилон
- ПЛО - җәмәгать транспортын көтү павильоны составындагы пилон
- АФЩ - щитлы афиша корылмасы
- АФТ - афиша тумбасы
- КУ - коммуникация күрсәткече
- ЭКУ - электрон-цифрлы коммуникация күрсәткече
- РН - тукталыш пунктының җәмәгать транспортын көтү урынындагы түбәле реклама корылмасы

### II. Биналарда, корылмаларда урнаштырыла торган реклама корылмалары

- МФ - медиафасад
- РП - тукталыш пунктының җәмәгать транспортын көтү урынындагы түбәле муниципаль тукталыш корылмасында реклама панеле

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 10 февралендәге
318 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәре территориясендә коммуникация күрсәткече рәвешендәге реклама корылмаларын урнаштыруның адреслы планы**

| Тәртип номеры | Схемадагы номер | КК* башкару вариантлары | Район, урам (проспект, тыкрык), йорт | Урнашу урынын аныклау | Яклар саны | Мәгълүмат кырларының мәйданы, кв.м | Мәгълүмат кырының тибы** | | Схеманың бит номеры |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | А ягы | Б ягы | |
| **1** | **2** | **3** | **4** | **5** | **6** | **7** | **8** | **9** | **10** |
| «15 | КУ-15 | 3 | Совет районы Җиңү проспекты, 101 й. | | 2 | 10,08 | Щит өслек | Щит өслек | 103» |

___________________________